**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1052 номерлы һәм 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы һәм 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 17 пункттагы «110» һәм «385» саннарын тиешенчә «113» һәм «382» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 24 сентябрь
№ ПУ-892